Ислам-Нур

ДУХОВНО-ПРОСВЕТИТЕЛЬСКАЯ ГАЗЕТА РЕГИОНАЛЬНОГО
ДУХОВНОГО УПРАВЛЕНИЯ МУСУЛЬМАН
САМАРСКОЙ ОБЛАСТИ
И САМАРСКОЙ СОБОРНОЙ МЕЧЕТИ

№ 22 (81), 30 ноября 2012 г.
15 Мухаррам 1434 г.

Политика

«Мы категорически против ввода в школы священнослужителей в должности завучей»

15 ноября состоялось совместное заседание общественной комиссии по образованию при комитете по образованию и науке и общественной комиссии по культуре при комитете по культуре, спорту и молодежной политике. Главной темой для собравшихся стало обсуждение воспитательного процесса в школах Самарской области.

В заседании приняли участие председатель комиссии по образованию Игорь Вершинин, депутаты, преподаватели школ, специалисты регионального министерства образования, общественных организаций и представители разных конфессий.

Поводом для собрания стала инициатива депутата Дмитрия Сивиркина по рассмотрению возможности введения в школах региона должности завучей - духовных наставников. Председатель Регионального Духовного управления мусульман Самарской области, муфтий Талип-хазрат Яруллин, выступая на заседании, поддержал мнение о том, что школа должна оставаться светской. Вашему вниманию предлагаем текст этого выступления.

- Депутат губернской Думы, господин Сивиркин вышел с предложением введения в школах на должность заместителя директора по воспитательной работе священнослужителей. Это противоречит основному закону Российской Федерации, где четко обозначено, что Россия – светское государство, и религия отделена от государства.

В Самаре созданы все условия для преподавания религиозных норм поведения. У нас в каждом храме-мечети проводятся воскресные уроки для разных категорий людей, желающих обучаться, в том числе и для детей.

Религиозное воспитание – дело добровольное.

Господин Сивиркин ссылается на Чечню, где Рамзан Кадыров ввел в школах эту должность. Во-первых, Чечня не образец для подражания, во-вторых школа должна заниматься обучением детей. Вводя должности священников в школах мы посеем зернышки раздора в неокрепших душах детей.

Школа должна оставаться светской, и мы не должны давать детям повод для раздора.

Региональное Духовное управление мусульман Самарской области категорически против ввода в школы священнослужителей в должности завучей.

Шамил БАГАУТДИН.

Туган як

Иске Ярмәк авылы 275 еллыгын билгеләде

Самар өлкәсенең Иске Ярмәк авылына 275 ел, авыл мәчетенә 20 ел тулды. Шушы ике дата уңаеннан тантанада катнашкан “Ислам-Нур” гәҗите мөхәррире Фәрид Ширияздан үз фикерләре белән уртаклашты.

- Һәркем үз төбәген, туган җирен якын күрә, аның турында якты истәлекләр саклый. Әлбәттә, безнең Иске Ярмәк авылы да истәлекләргә бик бай. Узган һәр чорның, һәр дәвернең җитди вакыйгалары хәзер инде авыл тарихына әверелгәннәр. Кызганыч ки, бүгенге көндә аларның күп өлеше сакланмаган, югалган. Менә бу бәйрәм - ул тарихыбызны барлау, динне күтәрү, халыкның бердәмлеген үстерү һәм читтә яшәүче якташларыбызның авыл көнкүреше белән кызыксынуын көчәйтү, туганлык хисләрен яңарту рәвеше.

Аллага шөкер, алдынгы фикерле кешеләр авылыбызның тарихын булдыра алганча элгәредән үк язып, теркәп барганнар. Соңгы вакытта аңа карата кызыксыну әле тагын да артты. Исән булсак, Алла теләсә, авылыбыз тарихы турындагы китап киләсе елга басылып чыгар, дип өметләнәбез.

Авылда үткән балачакны искә алганда, иң элек авыл мәчете, аннан кайтып килүче ак сакаллы, мөлаем йөзле мәчет картлары күз алдына килә. Авылга кайтканда ерактан мәчетнең айлы манарасы каршы ала һәм киткәндә озатып кала иде. Гомумән, авыл тарихын мәчетләрдән, диннән, дини истәлекләрдән башка күз алдына китерү дә мөмкин түгел. Менә хәзерге тарихны барлау, яңа төзелгән мәчетнең 20 еллыгын үткәрү - ул динебез Исламны үстерү, халкыбызның рухын баету, ялгышларыбызны төзәтү, уңышларыбызны барлау рәвеше.

Мәчет тарихы ике дистә ел белән генә чикләнми, билгеле. Инкыйлабтан соң авыл мәчетләреннән склад, тавык фермасы, клуб ясыйлар.

Заманында Иске Ярмәк авылында дүрт мәчет булып, алар халыкның иманын ныгытып, тәрбия һәм гыйлем учагы булып торганнар. Манараларын кисеп, складларга, мал абзарларына әверелдереп һәм яндырып юк итсәләр дә, барыбер халкыбыз күңелендәге иман нурын сүндерә алмаганнар. Мәчет булмаган чорда да халык аны булдыру хыялы белән яшәгән.

Шулай булмавы мөмкин дә түгел, чөнки Иске Ярмәк авылы заманында төбәгебезнең дин үзәге, дин чыганагы булган. Биредә ахун Хөснулла хәзрәт яшәгән һәм хезмәт иткән. Ахунлы авыллар сирәк, шул сирәкләрнең берсе - безнең Иске Ярмәк.

Җирле тарихта тирән эз калдырган бу бөек шәхес турындагы истәлекләрнең күбесе хәзергәчә сакланмаган, югалган.

Без еш кына туган ягыбызның тарихы серле һәм бай булуын телгә алабыз. Кызганыч ки, бу хакта безнең белгәннәребез бик чамалы, ә кыйммәтле хәбәрләр югалган. Күп нәрсәне ачыклыйсы, тулыландырасы бар.

Мәсәлән, Камышлы төбәгендә Русиядә беренче булып нефть ятмалары табылган һәм аны кудыру заводы корылган. Бу эшне волость старшинасы Надыр Уразмәтов башлап җибәргән. Соңрак бу җирләргә Петербурдагы Фәннәр Академиясенән Алёхин, Паллас, Рычков үзләренең экспедицияләрен оештырып, тирән эзләнүләр алып барганнар. Нәтиҗәдә алебастр, күкерт, сланец һәм башка табигый байлыкларны да тапканнар.

(Ахыры 2нче биттә)